ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МОНАШЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ТАТАР КОКШАНЫ АВЫЛЫ
ГРАЖДАННАРЫ ҖЫЕНЫ

КАРАР

30.11. 2023 ел № 8

2024 елга Татарстан Республикасы
Менделеевск мунициципаль районы
Монашево авыл җирлегенең Татар Кокшаны авылында
гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Татар Кокшаны авылы гражданнары җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Монашево авылы җирлегенең Татар Кокшаны авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләреннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, ә күп балалы гаиләләрдән 50% ка киметеп 500 сум күләмендә билгеләргә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә

1.Кокшанка елгасының үзәнен үзгәртү;

2.Янгын сүндерү машинасы һәм буяу өчен запас частьләр (батарея, стартер) сатып алу;

3.Янгын сүндерү машинасына хезмәт күрсәтүче шоферның хезмәтләре өчен түләү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Монашево авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Монашево авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Иосифов